ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.10.2020 г.Лениногорск № 9

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналары картасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып һәм җәмәгать тыңлауларында Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналары картасына үзгәрешләр кертү Проектлары буенча фикер алышу нәтиҗәләрен карап, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына кертергә

– ТР, Лениногорск ш., Васильев ур., 1а з/у, 1а адресы буенча урнашкан №16:51:011801:683, №16:51:011801:402 җир участокларына карата, күпфатирлы торак йортлар төзү максатыннан, территориаль Д-4 (спорт һәм спорт-тамаша объектлары урнаштыру зонасы) Ж-2 территориаль зонасына (3-5 катлы аз катлы һәм азкатлы торак йортлар төзү зонасы) үзгәртергә.

2. Җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссия Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналары картасына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә һәм

яңартылган документларны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль геомәгълүмат системасында (ФГИС РТ) урнаштырырга.

3. Карарны (халыкка хәбәр итәргә) Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында: http://Leninogorsk.tatar.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы В.Н.Маркеловага йөкләргә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры — Р.Г. Хөсәенов